ЧИТАЕМ НА ТАТАРСКОМ

# "Галиябану" — Мирхәйдәр Фәйзи

23 октябрь 2026




Иллюстративное фото

**Сегодня предлагаем вам прочитать и прослушать пьесу классика татарской драматургии Мирхайдара Файзи "Галиябану". Она была написана в 1916 году, а через год профессиональная труппа показала спектакль в Оренбурге. Это первая татарская музыкальная драма.**

"Галиябану" – история любви, которую можно сравнить с шекспировской трагедией "Ромео и Джульетта". Двое молодых людей мечтают быть вместе, но на пути их счастья встают богатство, родительская воля и ревность.

Текст пьесы сокращён и адаптирован для изучающих татарский язык. Также мы предлагаем перевод ключевых слов и фраз.

— Безнең Галиябанунын кашы кыйгач ук түгелдер бит? — дип сорый Бәдри.

— Кыйгач инде, кап-кара сызылып киткән кыйгач каш, әтисе.

— Кара син дуңгызларны! Туганнан бирле алдында торган атасы белми, ә алар барын да җентекләп беткәннәр! — дип көлә Бәдри.

Бераздан аның күңеленә бер уй килә. Бәлки, җырлаучылар арасында авылның иң бай егетләреннән берсе — Исмәгыйль дә бардыр? Исмәгыйльнең Галиябануга күзе төшкәнен Бәдри ишеткәләгән иде.

Исмәгыйль — күп җирләре булган, үз сүзен үткәрергә өйрәнгән бай егет. Бәдри өчен аннан да яхшырак кияү табу кыен. Ул кызын Исмәгыйльгә бирсә, үзенең дә авылдагы дәрәҗәсе күтәрелер дип өметләнә.

— Үзе бай, үзе хуҗа. Дөньяны дер селкетеп тора, — дип мактый ул егетне.

Галимә дә каршы түгел. Ире белән икесе Галиябанунын Исмәгыйльгә мөнәсәбәтен белергә телиләр. Бәдри кызының әйберләрен караштыра башлый. Өстәлдә яңа чигелгән кулъяулык таба.

— Башланган, чигә башланган бит, Ходайга шөкер! — дип сөенә ул.

Анынча, Галиябану бу яулыкны Исмәгыйльгә бүләк итәргә әзерләгән. Галимә дә шулай уйлый. Икәүләп тагын эзләнәләр һәм бер хат табалар.

Бәдри хатны укырга тели, әмма кичен күзләре начар күрә. Галимә исә бөтенләй укый белми. Шулай да ире аны хаттагы хәрефләрне танырга мәҗбүр итә. Хатыны бер хәрефне таякка, икенчесен чалгыга, өченчесен балык тоту җәтмәсенә охшата. Бәдри шулардан үзенә кирәкле нәтиҗә чыгара: хатны, һичшиксез, Исмәгыйль язган!

— Исмәгыйль инде, Исмәгыйль! Аллага шөкер! — дип куана ул.

Алар хатны да, яулыкны да урынына куялар.

— Егет тә сөя, кыз да сөя, без ике баштан дүрт куллап риза. Туй итәсе генә калды! — ди Бәдри.

Алар шунда ук туйга әзерләнә башлыйлар. Галимә кунакларга казлар җитәрме дип борчыла. Бәдри үзенә яңа чалбар тектерергә уйлый. Галиябану энесе Садрыйга

камзул, Галимәгә күлмәк кирәк булачак. Хәтта бай кияүне иске мунчага кертмәү өчен яңа мунча эшләтергә дә җыеналар.

Әлегә алар Галиябануның үзеннән бернәрсә дә сорамаганнар, әмма алар кызларының кемне яратуын беләбез дип уйлыйлар.

Төн җитә. Кинәт тыштан акрын гына сызгырган тавыш ишетелә.

— Килде, килде! — дип ашыга Бәдри.

— Исмәгыйль, Исмәгыйль! — ди Галимә.

Алар, яшьләргә комачауламас өчен, бүлмәдән чыгып китәләр.

Озакламый Галиябану керә. Ул кулъяулыгын алып, чигү җебенең очларын төйни. Аннары өстәлдәге хатны күреп ала һәм ертып ташлый.

Бу хатны Исмәгыйль язган икән. Галиябану аны бөтенләй яратмый. Бай егет күптәннән кыз артыннан йөри, сәламнәрен җиткерә, аңа якынаерга тырыша. Галиябану исә аны күрергә дә теләми.

— Хатлары белән, сәламнәре белән, җырлары белән тәмам теңкәмә тиде инде Исмәгыйль абый, — дип зарлана ул.

Аның йөрәгендә башка кеше — Хәлил. Галиябану аны унөч яшеннән бирле ярата. Хәлил бай булмаса да, матур, уңган егет, оста гармунчы. Кыз өчен аның мәхәббәте Исмәгыйльнең бөтен байлыгыннан кадерлерәк.

Шулвакыт тагын сызгыру ишетелә. Галиябану тәрәзәгә килә. Тышта ай яктысы. Кыз сызгыруның Хәлилнеке икәнен аңлый.

Бераздан таныш тавыш җырлап җибәрә:

*Билемдәге ал билбавым*
*Тормый кыстырган җирдә;*
*Үзе чакыра, үзе кача,*
*Галиябану, сылуым-иркәм,*
*Чыкмый сызгырган җиргә.*

Галиябану да җыр белән җавап бирә:

*Йөгереп төштем су буена,*
*Суда кошлар йөзә дип;*
*Чыкмыйсың дип үпкәләмә,*
*Җаныем-бәгърем, сылуым-иркәм,*
*Куркам кеше сизәр дип.*

Хәлил тәрәзә янына килә. Алар бер-берсенә карап җырлашалар. Егет сөйгән кызын бик сагынган. Икәү генә калгач, алар сөюләрен яшермиләр. Хәлил кыздан үзен чынлап яратамы икәнен сорый. Галиябану уңай җавап бирә. Икесе дә бәхетле. Ләкин Хәлилнең күңелендә борчу бар. Ул Исмәгыйльнең Галиябану тирәсендә йөрүен белә. Су буенда да Исмәгыйль яшьләр арасына кергән, Хәлил аның белән чак кына талашмаган.

— Мин мәңге аңа барачак түгелмен, — ди Галиябану. — Әтиләр кыстап йөдәтә башласалар, син миңа ярдәм итәрсең бит, Хәлил?

— Теләсәң, мин иртәгә үк сиңа яучы җибәрәм.

— Яхшылык белән бирмәсәләр, минябышып чыгам.

Алар бер-берсеннән аерылмаска сүз бирәләр. Хәлил иртәгә үк яучы җибәрергә вәгъдә итә. Галиябану да ашыктыра: Исмәгыйль өлгергәнче, бу эшне хәл итәргә кирәк.

Шулчак әтәч кычкыра. Таң якынлаша. Галиябану сөйгәненә үзе чиккән кулъяулыкны бүләк итә. Бу яулык аларның мәхәббәте һәм биргән вәгъдәләре билгесе булырга тиеш.

## Икенче пәрдә

Икенче көнне Бәдри шәһәргә барырга җыена. Аның хатыны Галимә өйдә җеп эрләп утыра. Икесе дә бик шат: алар Галиябануның бай Исмәгыйльгә кияүгә чыгачагына шикләнмиләр.

Бәдри кызының кулъяулыгын искә төшерә. Ул яулыкны элекке урынында таба алмый. Димәк, Галиябану аны сөйгән егетенә бүләк иткән!

— Яулык күптән Исмәгыйльнең кесәсендә ята инде! — дип сөенә Бәдри.

Чынлыкта исә Галиябану кулъяулыкны Хәлилгә бүләк иткән иде, ләкин ата-анасы моны белми.

Бәдри белән Галимә булачак кияү, туй турында сөйләшәләр.

— Мондыйны инде, этисе, шәм ягып эзләсәң дә тапмассың. Бай, төскә дә ярыйсы гына, — ди Галимә.

— Кесәң калын булса, йөрәкнең чуарлыгы күренми ул. Алтын күзнең явын ала, диләр бит, — дип җавап бирә Бәдри.

Алар үзләренең яшь чакларын да искә төшерәләр, көлешәләр. Бәдри хәтта хатынын кочакларга маташа.

— Китче, очынма әле, сакаллы сабый! — дип көлә Галимә.

Шул арада Галиябану өйгә керә. Әтисенең шәһәргә китәргә җыенуын ишеткәч, ул чигү өчен җеп алып кайтуын сорый. Галимә исә кызына матуррак әйберләр дә алырга мөмкин булуын әйтә.

— Бердәнбер кызына атаң да каршы килмәс. Яшең дә җитмәде түгел; Ходай бәхетеңне бирсен инде, балакаем, — ди анасы.

Галиябану аптырап кала. Әнисе ни өчен кинәт туй турында сөйли башлады икән?

Галимә сүзен дәвам итә:

— Атаң әйтә, яшьләрнең күңелләре бер нәрсәгә төшсә, аларны аерып булмый, ди. Ялгыз бер кызыбыз, без анның теләгенә каршы килеп йөрмәбез инде, үзе дигәнен эшләрбез, ди.

Бу сүзләрне ишеткәч, Галиябану бик шатлана. Димәк, әти-әнисе аның Хәлилне яратуын беләләр һәм аларның өйләнешүенә каршы түгелләр!

— Минем... теләгемә каршы килмәсәгез, бәхетле булыр идем, — ди әйтеп сала кыз.

— Безнең дә бар теләгебез синең бәхетле булуың, балакаем. Сүзеңне әйтеп бетер, кызым, миннән тартынма.

— Минем киенү-ясанудан башка бер теләгем бар... Тик әйтергә генә оялам... Үзегез дә беләсездер инде...

— Без синең ниятеңне белдек. Ходай ак тормышлар бирсен инде, — ди Галимә.

Ана белән кыз бер-берсен аңладык дип уйлыйлар. Ләкин Галимә Исмәгыйль турында, ә Галиябану Хәлил турында сөйли.

Әнисе чыгып киткәч, Галиябану шатлыгыннан сикергәли башлый.

— И, мин нинди бәхетле, нинди бәхетле! Бу кадәр бәхетле булырмын дип уйламаган идем!

Ул әти-әнисенең үзенә Хәлил белән кавышырга рөхсәт бирүенә сөенә. Хәзер Хәлил яучы җибәрсә, барысы да яхшы булачак.

Шулвакыт өйгә авылда яучы булуы белән танылган Бәдига карчык керә.

Галиябану аны күрүгә каршы йөгерә:

— Әби, миңа яучыга килдеңме әллә?

— Әйе, әйе, кызым, синең башыңны ашарга килдем – ди яучы карчык.

— Хәлилдән килгән булсаң, ашый бир!

— Хәлилдән, Хәлилдән. Сине башкага әрәм итәмме соң!

Галиябану сөенеп Бәдига карчыкны кочаклый. Карчык Хәлилнең аңа күп сәлам әйтүен, кичен су буена уенга чакыруын җиткерә. Озакламый Галимә керә. Бәдига үзенең ни өчен килүен аңлата:

— Мин сезнең кызыгыз Галиябануга яучы булып килгән идем. Яшьләрнең бер-берсенә вәгъдәләре дә бар икән. Инде эш сездән генә калып тора.

Нәкъ шул вакытта Бәдри ат белән шәһәргә чыгып китәргә тора. Галимә аны тәрәзәдән чакырып туктата.

— Атасы! Тиз генә өйгә кереп чык әле. Бәдига абыстай килгән иде!

Бәдри яучыны күргәч, сөенә. Аның күптән көткән кунагы килгән бит! Бәдига карчык яшьләрнең бер-берсен яратуын, вәгъдә бирешүләрен сөйли. Ул Хәлилнең исемен әйтми, чөнки Галиябануның кемне сайлаганын ата-анасы белә дип уйлый.

Бәдри дә егетнең исемен сорамый. Ул Исмәгыйль турында сүз барганына тулысынча ышана.

— Без кызыбызның теләгенә каршы килмибез. Үзләре табышкан, үзләре вәгъдә куешкан. Шулай булгач, Ходай бәхетләрен бирсен диюдән башка сүзебез юк, — ди Бәдри.

Бәдри исә шәһәргә китә. Галиябану тәрәзәдән әтисенең китеп баруын күргәч, ул аңа рәхмәтләр әйтеп кала. Галиябану үзен дөньядагы иң бәхетле кыз дип саный. Ләкин бу өйдә зур ялгышлык килеп чыкканын әле беркем дә аңламый. Галиябану белән Хәлилнең бәхетенә шатланган Бәдига ярдәмчелек эшен башкардым дип уйлый. Ә Бәдри белән Галимә кызларын Исмәгыйльгә бирергә ризалаштык дип сөенәләр.

## Өченче пәрдә

Су буенда, таллар арасында Исмәгыйль ялгызы йөри. Ул бик ачулы. Авылда Галиябануны Хәлилгә ярәшкәннәр дигән хәбәр таралган. Исмәгыйль моңа ышанырга теләми.

Ул Галиябануны күптән үзенеке дип саный. Байлыгы һәм дәрәҗәсе белән горурланган егет өчен кызның башка кешене сайлавы — зур хурлык.

— Мин барында, ничек аңа бирергә кыйсыннар? — дип ярсый ул. — Әллә нинди бер малай минем белән ярышмаска тиеш!

Шулчак суга баручы Галиябану күренә. Аның иңендә көянтә-чиләк. Исмәгыйль таллар арасыннан чыга һәм кызның юлын бүлә.

— Юлыңа гөлләр үссен, Галиябану!

Кыз салкын гына рәхмәт әйтеп китмәкче була. Әмма Исмәгыйль аны туктата.

— Сезнең тирәдә козгыннар йөри, диләр. Расмы әллә шул сүз?

— Рас иде дә, котылдым инде.

— Теләмәдеңмени? Хәлилнеме?

— Юк, Исмәгыйльне теләмәдем.

Бу җавап Исмәгыйльне тетрәндерә. Ул Галиябануның кулыннан тотып ала.

— Син минеке булырга тиеш!

— Мәңге булмам. Мин Хәлилгә вәгъдә бирдем.

Исмәгыйль башта кызны үгетли, аннары куркыта башлый. Ул үзенең байлыгын, авыл халкы өстеннән булган хакимлеген искә төшерә.

— Минем исемем ишетелгәндә, бөтен тирә халкы тетрәп тора. Минем күңелемне егып, башкага китүнең ахыры бик яхшы булмаячак, уйла, Галиябану!

— Зинһар, Исмәгыйль абый, мине җәберләмә, мин Хәлилне сөям. Юкка минем юлымны бума!

Ләкин Исмәгыйль тыңламый. Кыз китәргә җыенгач, ул аның башыннан шәлен тартып ала. Галиябануның көянтә-чиләкләре җиргә төшә. Исмәгыйль исә аны мыскыллавын дәвам итә. Хәлилнең ярлырак булуын искә төшереп, Галиябануны түбәнсетә.

— Бар, әнә теге чүплек башындагы өйдә сине килен итеп көтеп торалар, ди.

— Миңа шул да ярый. Анда синең эшең булмасын!

Шулвакыт Хәлил килеп җитә. Ул Исмәгыйльнең кулыннан Галиябануның шәлен тартып ала.

Галиябану Хәлилнең кочагына ташлана.

— Тыныч бул, Галиябану, — ди Хәлил. Аннары Исмәгыйльгә борыла: — Бел шуны: башың ике булса, кер безнең арага!

Хәлил Галиябануны алып китә. Исмәгыйль исә алар артыннан ачу белән карап кала.

— Әгәр шушы Хәлилнең кулыннан Галиябануны тартып ала алмасам, Исмәгыйль исеме миңа хәрам булсын!

Бераздан Хәлил белән Галиябану яңадан су буена киләләр. Кыз бик борчыла. Ул Исмәгыйльнең үч алырга тырышачагын сизә. Ул этисенең байлыкка кызыгуын белә. Исмәгыйль аны үз ягына аударса, ата-анасы кызны өйгә бикләп, көчләп кияүгә бирергә мөмкин. Хәлил бераз уйланып тора да бер юл тәкъдим итә. Әгәр Галиябануның әти-әнисе сүзләреннән кире кайтсалар, кыз аларга каршы

килмәгән булып кыланырга тиеш. Шулчак аны бикләмәсләр. Ә төнлә Хәлил килеп, аны Көмшәр авылына алып китәр. Анда никах укытырлар.

— Юлыма таш яуса да бармый калмам, — дип вәгъдә бирә Хәлил.

— Ярый, мин күнәм. Синеке булып калыр өчен тау тишеп чыгарга да ризамын, — ди Галиябану.

Алар аерылышалар.

Кич җиткәч, Бәдри белән Галимә бакчага чыгып утыралар. Алар һаман да кызларын Исмәгыйльгә бирәбез дип уйлыйлар. Хәзер туйлык һәм мәһәр өчен күпме акча сорарга икәнен киңәшәләр.

Шулвакыт бакчага Исмәгыйль килеп керә. Бәдри белән Галимә аны күреп бик сөенәләр. Әмма Исмәгыйльнең кәефе бөтенләй башка. Ул Галиябануның Хәлилгә ярәшелгәнен белә һәм ата-анасын алдауда гаепли.

— Мине танымый йөрисез икән әле. Менә танырсыз! — дип кычкыра ул.

— Ни булды? — дип аптырый Бәдри.

— Галиябануны Хәлилгә ярәшкәнсез!

Бәдри белән Галимә бер-берсенә карап калалар. Алар Хәлил турында бернәрсә дә белмиләр.

— Юк, юк! Хәлил дигәнне уйга да кертмәнебез юк, — ди Бәдри. — Кызыбыз да син дип үлеп тора!

Галимә дә сүзгә кушыла:

— Соң, вәгъдә билгесе итеп үзеңә чиккән яулык та бирде ләбаса.

— Чиккән яулык?.. Алайса ул яулык Хәлилдә, — ди Исмәгыйль.

Шунда гына ата белән ана үзләренең нинди зур ялгышлык эшләгәннәрен аңлыйлар. Кызларының сөйгәне Исмәгыйль түгел, Хәлил булган икән! Бәдига карчык та нәкъ Хәлилдән яучы булып килгән!

Бәдри бик нык ачулана. Ул Галиябануны Хәлилгә бирергә җыенмавын әйтә. Исмәгыйль исә үзенең ниятеннән кире кайтмаячагын белдерә.

— Галиябану миңа булырга тиешле. Мин үземнең исемемне әллә нинди малайлардан таптатмас өчен һәртөрле юлга керергә әзер, ди ул һәм Бәдригә борылып, — Әгәр Галиябануны Хәлилдән айнытып, иртәгә үк миңа никах укытып бирә алсаң, туйлык, мәһәрләрдән башка үзеңә мең сум.

Бәдри ишеткәненә ышанмый тора.

— Мең... мең тәңкә?

— Ишлисең бит, Бәдри абзый, шуны?

— Булды, кыз синеке!

Исмәгыйль китә. Бәдри исә мең сум турында уйлап кала.

Шул арада Галимә Галиябануны алып керә. Бәдри кызына аны Исмәгыйльгә бирергә җыенуларын әйтә.

— Ул нинди кияү булсын? Бер бирдегез бит инде мине, әткәй, — ди Галиябану.

— Кемгә бирдек?

— Хәлилгә.

— Юк, без сине Хәлилгә биргәнебез юк. Исмәгыйльгә дип бирдек.

Галиябану бөтенесен аңлап ала. Ул ата-анасының ялгышуын белмәгән икән. Кыз елап, үзен көчләп кияүгә бирмәүләрен үтенә.

— Әти, әни, зинһар дим, мине җәберләмәгез. Минем бәхетемә аяк чалмагыз.

Галимә кызын үгетли. Аныңча, Исмәгыйль кебек бай егеткә кияүгә чыгу — зур бәхет.

— Мин сөймәгән кешемә ничек барыйм? — дип сорый Галиябану.

— Баргач сөярсең, карышма! — дип кычкыра Бәдри.

Галиябану ризалашмый. Ул Хәлилне яратуын һәм аңа биргән вәгъдәсен бозмаячагын әйтә. Бәдри ярсуыннан кызын кыйный. Галимә аны туктатырга тырышса да, ире аны да этеп җибәрә. Галиябану җиргә егылып, үксеп елый .
Бераздан кыз Хәлилнең сүзләрен искә төшерә. Ул ата-анасына риза булган булып кыланырга киңәш иткән иде. Галиябану башка чара калмавын аңлый.

— Ярар, аңладым, инде ихтыярыгыз . Сез минем өчен кайсы яхшы буласын артыграк беләсездер, — ди ул акрын гына.

Бәдри белән Галимә шатланалар. Алар кызларын күндердек дип уйлыйлар.

Шулвакыт Исмәгыйль кире килә. Бәдри аңа иртәгә үк никах укытырга җыенуларын әйтә.

— Эш булдымыни? — дип сөенә Исмәгыйль.

Галиябану дәшми. Исмәгыйль аңа кулын сузарга куша. Әти-әнисе дә кыстагач, кыз теләмичә генә кулын бирә.

— Җаның тыныч булсын, Исмәгыйль абый... — ди ул.

Исмәгыйль канәгать булып чыгып китә. Бәдри белән Галимә дә бәхетле. Ә Галиябануның күңелендә бер генә өмет кала: Хәлил сүзендә торсын, аны коткарырга килсен.

## Дүртенче пәрдә

Төн уртасы. Авыл йоклый, тирә-якны ай яктырта. Галиябануның өе янында Исмәгыйль йөри. Ул көнчелектән тынычлыгын югалткан. Кызның атасын акча белән үз ягына аударса да, Хәлилдән курка. Иртәгә никах укылганчы, Галиябануны кулыннан ычкындырырга теләми .

Кинәт кемнеңдер килгәнен ишетә. Бу — Хәлил. Исмәгыйль кесәсеннән револьверын чыгара һәм агачлар артына яшеренә.

Хәлил сак кына тәрәзәгә килә, шакый. Тәрәзә ачыла. Галиябану сөйгәнен күреп шатлана. Ул әти-әнисенең үзен Исмәгыйльгә көчләп бирергә җыенуларын, әмма ахырда риза булган булып кылануын сөйли.

— Мин атлар, кешеләр алып килдем. Куралар артында гына тора. Китик, алайса, тиз бул! — ди Хәлил.

Галиябану тәрәзәдән төшә. Әмма ул бик курка.

— Кешеләр килеп тотсалар, нихәл итәрбез?

— Бер дә каушама, нык бул! Атла аягыңны! Ул михнәткә түгел... бәхеткә таба, аны анык бел!

Яшьләр китәргә җыеналар. Шулчак аларның каршысына Исмәгыйль килеп баса һәм револьверын Хәлилгә төзи.

— Җибәр Галиябануны!

— Ник җибәрим мин аны?!

— Йә Галиябануны бирәсең, йә җаныңны!

Хәлил аны тынычландырырга тырыша. Аларның кечкенәдән бер-берсен яратуларын аңлата. Галиябану да ялвара. Ләкин Исмәгыйль берсен дә тыңламый. Ул кызны көч белән Хәлилдән аера.

Хәлил кинәт Исмәгыйльгә ташлана. Икәсе сугыша башлый. Револьвер җиргә төшә. Хәлил аны алып, Исмәгыйльгә төзи.

— Менә инде хәзер син минем кулда, — ди ул. — Ләкин синең кебек этне атарга хурланам.

Хәлил револьверны җиргә ташлый. Исмәгыйль шунда ук коралны күтәреп ала. Ату тавышы яңгырый. Хәлил җиргә егыла.

Галиябану сөйгененә ташлана. Сызгыруны ишетеп, Хәлилнең иптәшләре Сибгать белән Хәмзә йөгереп киләләр. Алар ярдәм чакыралар. Озакламый Бәдри, Галимә, авыл кешеләре һәм старшина килеп җитәләр. Исмәгыйль үзен акларга тырыша.

— Ул үзен үзе атты, — ди Исмәгыйль.

Аның байлыгыннан һәм дәрәҗәсеннән курыккан кайбер кешеләр дә аңа ышанырга әзер. Ләкин барысын да күргән Галиябану:

— Хәлилне Исмәгыйль атты! Ул атты Хәлилгә.

Шулчак Галиябану барысы алдында сөйли башлый:

— Мине Исмәгыйльгә көчләп бирмәкче булдылар. Мин мәңге аңа булачак түгел. Мин Хәлилне генә сөям. Ул минем өчен үзен харап итте! Әйт менә, Исмәгыйль абый, мин үтермәдем дип, минем күземә карап! Аны син үтердең! Син бит!

Исмәгыйль кызның күзенә карый алмый. Ниһаять, ул гаебен таный.

— Әйе, мин үтердем. Ачуымнан белешми аттым...

Старшина Исмәгыйльне кулга алырга куша. Аны алып китәләр.

Ә Хәлилнең хәле бик авыр. Галиябану аның янына тезләнә, кулын тота.

— Хәлил, китәсең бит...

— Галия... бану... — дип пышылдый егет.

Галиябану аның башын кочагына ала.

— Шулай ук аерылабызмыни?!

Хәлил соңгы көчен җыеп сөйгәненә эндәшә:

— Инде үлсәм дә... үкенмим, Галиябану, сылуым... иркәм...

Ул Галиябануның кочагында җан бирә.

Барысы да тын кала. Галимә елый, Бәдри Хәлилне алып китәргә әзерләнергә куша. Галиябану исә сөйгәненең яныннан китми.

— Хуш, җаным, — ди ул. — Галиябануыңа кавышу шатлыгы урынына синең җеназаң өстендә елап утырырга туры килә инде.

Ул Хәлил белән бергә җырлаган "Галиябану" көен искә төшерә. Кайчандыр мәхәббәт җыры булган бу көй хәзер аның өчен сөйгәнен искә төшерүче бердәнбер истәлеккә әйләнә.

*Ак атласым җитмәде,*
*Алмас кайчым үтмәде;*
*Унөч яшьтән бирле сөешеп,*

*Күзебез күзләрдән китмәде,*
*Ходаем* насыйп итмәде.

***



БУ ТЕМАГА:

"Галиябану" җыры (песня)

У нас есть и другие интересные татарские пьесы:

- Сүнгән йолдызлар (Угасшие звезды) — Кәрим Тинчурин
- Беренче театр (Первый театр) — Галиәсгар Камал
- Банкрот — Галиәсгар Камал
- Әлдермештән Әлмәндәр (Старик из деревни Альдермеш) – Туфан Миңнуллин
- Американ (Американец) — Кәрим Тинчурин

Если у вас есть предложения по текстам, то Вы всегда можете оставить их по адресу: **eydetat@gmail.com**

Заходите на **наш сайт**, каждый день вы найдете что-то новое и интересное! Также подписывайтесь на наши соцсети: мы есть в **Telegram-e**, **Instagram-e**, **Youtube** и **Тиктоке**.

Скоро – больше! До встречи, сау булыгыз!

This item is part of

Әйдә! Online

читаем на татарском

Азатлык Радиосы © 2026 RFE/RL, Inc. | Бар хокуклар сакланган